**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА АНДРЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АНДРЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Андреевка авылы **КАРАР**

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 1**

**«**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Андреевка авылы мәдәният йортында К.Маркс урамы 2нче йорт адресы буенча Буранов урамы буенча 2а-20 санлы йортлардан, К.Маркс урамы буенча 35-75 санлы йортлардан, Н.И. Маслаков урамы буенча 48-90 нчы йортлардан, Басу урамы буенча 20-58 нче йортлардан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 10 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка К.Маркс урамы 2нче йорт адресы буенча Андреевка авылы мәдәният йортында Гагарин урамы 1-8 санлы йортлардан, Зайкин урамы 2-17 санлы йортлардан, Ленин урамы 3-47/2 санлы йортлардан, Бакча урамы 1-27 санлы йортлардан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2019 елның 10 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка К.Маркс урамы 2нче йорт адресы буенча Андреевка авылы мәдәният йортында К.Маркс урамы буенча 5-33 санлы йортлардан, Н.И. Маслаков урамы буенча 2-44 нче йортлардан, Басу урамы буенча 1-18 нче йортлардан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын билгеләргә

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Андреевка авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирленең Андрревка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидтан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, студентлардан, көндезге уку формасы буенча укучылардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Андреевка торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлап карап тоту, таш, ватык кирпеч, грунт, вак таш, ком (сатып алу, ташу, җәю).

« ЗА» «ПРОТИВ».

« РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Андреевка авыл җирлеге башлыгы Егорова Н.И.